**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» апреля 2020 с. Тюлячи № 173

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 453 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга соцпиаль ярдәм чаралары күрсәтү турында карарына үзгәрешләр кертү хакында»

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына ана (гаилә) капиталы чараларын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 453 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибе:

А) 2.1 пунктның «г» пунктчасында «Опекага алынган балага компенсация билгеләү өчен өстәмә рәвештә җирле үзидарә органнарының баланы опекага алу турында карарыннан өземтә тапшырыла» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары И.Ә. Миңнегуловка йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хажипов